**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ТУЙМЕТКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Школьная ,дом 4, с.Туйметкино, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108

тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90. Tuy.Cmn.2@tatar.ru

№ 56 19 май 2022 ел

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 апрелендәге 22 номерлы «Туймәт авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Туймәт авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2022 елның 1 апрелендә кабул ителгән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 апрелендәге 22 номерлы карары белән расланган Туймәт авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Туймәт авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәнең 7 бүлекнең «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьга кадәр) үз чыгымнары, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше,

пайлары), санлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-бирешкә кадәрге соңгы өч ел өчен әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми керемённән артып китсә, һәм алыш-биреш кылу өчен чараларны алу чыганаклары турында белешмәләр».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Туймәт авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Б. Кәримов